**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЧҮРИ-БУРАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

3 сентябрь 2019 ел №10

**Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

“Федераль мәгълүмат адреслы система турында” һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законнарга үзгәрешләр кертү хакында” 2019 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итә:

1.Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чүри-Бураш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 14 декабрендәге 20 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» гы карарына 1 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1.5 пунктның өченче абзацында "планлаштыру структурасы элементы (кирәк булганда), урам-юл челтәре элементы" сүзләрен "урам-юл челтәре элементы һәм (яки) планлаштыру структурасы элементының атамасы (кирәк булганда))" сүзләрнә белән алыштырырга;

б) 1.5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"адресация объекты-капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект;".

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Чүри-Бураш авыл**
**җирлеге башлыгы** **И.Р.Мифтахов**